ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

КАРАР 17.01.2020

ПОСТАНОВЛЕНИЕ № ПГ-2

**2020 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Актаныш муниципаль районының төп чаралары планын раслау турында**

Татарстан Республикасының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү территориаль ярдәмче системасының һәм гражданнар оборонасы органнарының һәм Актаныш звеносының әзерлек дәрәҗәсен тагын да күтәрү максатларында Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Расларга:

- 2020 елга Актаныш муниципаль районының гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә төп чаралар планы;

-2020 елга Татарстан Республикасы табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының идарә органнарын, гражданнар оборонасы көчләрен һәм Актаныш звеносын әзерләү буенча кушымталар.

2. Муниципаль район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә югарыда әйтелгән планның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

3. Авыл җирлекләре башлыкларына, муниципаль район оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә 2020 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча төп чараларның тиешле планнарын билгеләнгән тәртиптә эшләргә һәм гамәлгә кертергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Актаныш муниципаль районы Башлыгы — Э.Н. Фаттахов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ * СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ОГРН 1051667009734 ИНН 1604006751